# МИНЕМ АПАМ

**Киң күңелең юмартлыгың өчен
Кояш белән сине тиңлибез
Исәнлек, муллык куанчылы
Озын-озак гомер телибез.**

Үзем белән бер туган апам — Каримова Зәкия Сибгат кызы турында кыскача гына булса да язып үтмәкче булам. Ул Әсәкәй районы, Карамалы авылында 1925 елның 15 августында, кызарып кояш чыкканда, әниемнең икенче баласы булып, якты доньяга килә.

Матур-чибәр озын чәчле яшь үсмер кызның яшьлеге сугыш елларына туры килә. Авылда малайларны, кызларны ул вакытта ФЗОга җибәрәләр, тимер юлында эшләтәләр, акуп казыталар. Озак кына газапланганнан соң, ахырда качып кайтып китәләр. Ул вакытта ни ашарга, ни киярга кытлык була. Авылга кайткач колхозда башта прицепчик, анан соң Әминә апа белән тракторда эшли. "Фронт өчен" дигән лозунг астында көнә-төнә эшләп, икмәк үстереп фронтка озаталар. 1945 елда сугыш бетә. Әбезнең булачак җизни, Каримов Идрис күкрәгә тулы орден-медальләр белән армия сафларыннан отпускага кайтып төшә.

Апа үзенең матур тавышлы, моңлы җырлары белән, яшь егетнең йөрәген яулап ала. Кичке уеннан соң алар бер-берсенә көтәргә дип вәгъдә куешып аерылышалар.Алар эш ягыннан да, бар яклап та пар килгән булалар. 1947-енче елда җизниебез армия сафларыннан исән-имин кайта. Алар шул ук елны өйләнешәләр. Безнең апа ишле семьяга килен булып төшә. Җизни армиядән кайткач та, бик нык эшкә чума, чөнки аны колхоз җитәкчесе итеп, сайлап куялар. Шулай итеп апа белән җизни матур итеп 52 ел бергә гомер кичерәләр. Дүрт кыз, ике малай үстерделәр, укыттылар. Хәзер барысының да үз тормышлары, бик яхшы торалар. Ни кызганыч, апаның ике улыда, җизнидә дөнья куйдылар.Хәзер апаның 11 оныгы, 10 оныкчыгы бар, шулар белән бергә сөенеп яши.



Ул үзе уңган, үзе булган пешергән ризыклары татлы. Әле шушы яшендә дә, өендә чисталык, пөхтәлек исе аңкып тора. Хәзерге вакытта Әниемнең 8 баласыннан апа белән икәү генә калдык.

Апага минем теләгем шул: Агач тамыры, үзенең яфраклары белән күзгә күренмәгән, җепләр белән ничек тоташкан булса, Апа синдә безне, балаларыңны кияүләреңне, килennәреңне, оныкларыңны оныкчыкларыңны, шулай берләштереп торсаң иде.

Балаларыңның туган йортларының якты утлары беркайчанда сүнмәсен иде.Ходай тәгалә гаиләгезнең тамырына, күп елларга исәнлек-саулык, иминлек, бәхет-шатлык, бетмәс ныклы көч бирсен иде.

**На снимке:** Закия апа в окружении родных.

**Нурзимә ГИЗЕТДИНОВА,**
**Әсәкәй авылы.**



# Чай из блюдца

**Детство. Остались лишь воспоминания, о таком далеком времени…
Зима. Дома, занесенные по крышу снегом.
Запах кизяка и дров.**

Помню, как пили чай из блюдца. Это было в деревне, где жила тетушка. Утро нас будило запахом блинов и древесных углей. Ведерный, медный самовар уже урчал, прислонив кривую трубу к отверстию в печке. По случаю приезда гостей, тетушка доставала пачку чая со слониками и заваривала большой литровый чайник. Не торопясь, усаживались вокруг стола. Наливали чай из чашек в блюдца и пили степенно, с разговором. Кто-то держал блюдце на пальцах веером, кто-то за краешек. Было очень вкусно. Правда, иногда случались казусы. Какой-то зверь больно хватал за ногу под столом и чай с шумом проливался на скатерть. Оказывается, под столом высиживала яйца гусыня. Февраль. На улице морозно. Поэтому будущую мамашу заносили домой, в тепло, чтобы к первой травке появились гусята.

И было в этом чаепитии что-то ритуальное. Самовар собирал всю семью.

Нынешний перекус на ходу — это, увы, лишь уродливое подобие того чаепития из детства.

**Ф.ФАТТАХОВ.**






### Сөтле чәй (сөт өсте салган)

Татар халкы чәйне сөт яки сөт өсте белән эчәргә ярата. Гадәттә яңа сауган яки кайнаган (кайнар килеш) сөт алына. Сөтле чәй өчен чәй катырак итеп пешерелә. Чәйне табынга биргәндә чынаякка башта куе чәй, аннары сөт яисә сөт өсте салалар да самовардан кайнар су агызалар.

### Хуш исле чәй

Безнең тирә-юнебездә витаминнарга бай, хуш исле үсемлекләр үсә, алардан хуш исле чәй әзерләп эчәргә була. Болар — җир җиләге, кара карлыган, кура җиләкләренен яшел яфраклары. Агачыннан өзгән карлыган яфрагын салкын суда юып чәйнеккә салалар да өстенә кайнар су агызалар һәм 2 минутка ут өстенә куялар, аннары уттан алып, тастымал белән төреп, 3-5 минут торгызалар. Әзер чәйне чынаякларга бүлеп табынга бирәләр.

### Мәтрүшкә чәе

Киптергән яки яңа җыйган мәтрүшкәне ваклап чәйнеккә салалар һәм кайнар су агызып 1-2 минутка ут өстенә куялар. Аннары уттан алып, чәй яхшырак пешсен өчен, тастымал белән төреп берничә минут тоталар. Теләгән кешегә кайнатканда чәйнеккә бераз гына ваклап тураган башлы суган да сылырга мөмкин. Мондый чәйне сөт, сөт өсте белән эчәләр. Ул салкын тигәннән бик файда бирә.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ



(время местное)

| Февраль | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Өйлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 8-17 | 9-17 | 14-10 | 16-16 | 18-16 | 19-46 |
| 2 | 8-15 | 9-15 | 14-10 | 16-18 | 18-18 | 19-48 |
| 3 | 8-13 | 9-13 | 14-10 | 16-20 | 18-20 | 19-50 |
| 4 | 8-11 | 9-11 | 14-10 | 16-22 | 18-22 | 19-52 |
| 5 | 8-09 | 9-09 | 14-10 | 16-24 | 18-24 | 19-54 |
| 6 | 8-08 | 9-08 | 14-10 | 16-26 | 18-26 | 19-56 |
| 7 | 8-06 | 9-06 | 14-10 | 16-28 | 18-28 | 19-58 |
| 8 | 8-04 | 9-04 | 14-10 | 16-30 | 18-30 | 20-00 |
| 9 | 8-02 | 9-02 | 14-10 | 16-32 | 18-32 | 20-02 |
| 10 | 8-00 | 9-00 | 14-10 | 16-34 | 18-34 | 20-04 |
| 11 | 7-58 | 8-58 | 14-10 | 16-36 | 18-36 | 20-06 |
| 12 | 7-56 | 8-56 | 14-10 | 16-38 | 18-38 | 20-08 |
| 13 | 7-54 | 8-54 | 14-10 | 16-40 | 18-40 | 20-10 |
| 14 | 7-52 | 8-52 | 14-10 | 16-42 | 18-42 | 20-12 |
| 15 | 7-50 | 8-50 | 14-10 | 16-44 | 18-44 | 20-14 |
| 16 | 7-48 | 8-48 | 14-10 | 16-46 | 18-46 | 20-16 |
| 17 | 7-46 | 8-46 | 14-10 | 16-48 | 18-48 | 20-18 |
| 18 | 7-44 | 8-44 | 14-10 | 16-50 | 18-50 | 20-20 |
| 19 | 7-42 | 8-42 | 14-10 | 16-52 | 18-52 | 20-22 |
| 20 | 7-39 | 8-39 | 14-10 | 16-54 | 18-54 | 20-24 |
| 21 | 7-37 | 8-37 | 14-10 | 16-56 | 18-56 | 20-26 |
| 22 | 7-35 | 8-35 | 14-10 | 16-58 | 18-58 | 20-28 |
| 23 | 7-33 | 8-33 | 14-10 | 17-00 | 19-00 | 20-30 |
| 24 | 7-31 | 8-31 | 14-10 | 17-02 | 19-02 | 20-32 |
| 25 | 7-28 | 8-28 | 14-10 | 17-04 | 19-04 | 20-34 |
| 26 | 7-26 | 8-26 | 14-10 | 17-06 | 19-06 | 20-36 |
| 27 | 7-24 | 8-24 | 14-10 | 17-08 | 19-08 | 20-38 |
| 28 | 7-22 | 8-22 | 14-10 | 17-10 | 19-10 | 20-40 |

**Данные предоставлены Бугурусланским муфтиятом.**
**Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут.**

ТУГАН ЯК
РОДНОЙ КРАЙ

E-MAIL: tugan-iak-asekeevo@yandex.ru

**УЧРЕДИТЕЛЬ:**
ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:**
С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском районах.
Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ 56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

Газета отпечатана в Бугурусланской типографии. 461600, г. Бугуруслан, ул. Революционная, 14.

Цена свободная. ТИРАЖ: 2000 ЭКЗ.

**Главный редактор: Фарит НУГУМАНОВ**